**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет «Балтачевского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Молодежная, д **1**а , с. Балтачево Азнакаевского муниципального района **423302,** Тел. **(8-292) 4-47-23**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы, Молодежный урамы, **1**а **423302,** Тел. **(8-292) 4-47-23**

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от «30» гыйнварь 2024 ел № 1

2024 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары нигезендә «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында»гы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, 2024 елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 8 370,20 (сигез мең өч йөз җитмеш сум егерме тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. “ 2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Балтач авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик хакын раслау турындагы 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 нче номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2024 елның 01 февраленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм

Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Л.Л.Хәбипов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
«30» гыйнварь 2024 ел № 1

2024 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| **№** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4070,20 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1600,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2700,00 |
| **4** | **Барлыгы** | **8370,20** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта
« 30» гыйнварь 2024 ел № 1

2024 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| **№** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 1500,00 |
| 2 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2570,20 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1600,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2700,00 |
| **5** | **Барлыгы** | **8370,20** |